СОВЕТ ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

09.04.2026　　　Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.　　　№ 4-25

д. им. М. Вахитова

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының 2014 елның 22 ноябрендәге № 44-234 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының 2014 елның 22 ноябрендәге № 44-234 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) 2,5 процент - һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектларына карата, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш».

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» карар текстын яңа редакциядә расларга (1нче кушымта).

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе
ТР Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы　　　　　Ф.Р. Кәримов

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге Советының
09.04.2026 ел № 4-25 карарына
1 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә физик затлар мөлкәтенә салымны билгеләргә һәм гамәлгә кертергә

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:
1) 0,1 процент:
гаражлар һәм машина-урыннар;
мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалары;
2) 0,2 процент:
фатирлар, фатирларның бер өлеше;
бүлмәләр, бүлмәләрнең бер өлеше;
3) 0,3 процент:
торак йортлар, торак йортларның өлешләре;
әгәр мондый объектларның проектланучы билгеләнеше торак йорт булса, төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары;
составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;
4) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент;
5) Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән 1000 квадрат метрдан артык гомуми мәйданы булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) карата 2025-2027 еллар чорына - 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда - 2 процент.
6) Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына; Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата - 2 процент;
7) 2,5 процент - һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектларына карата, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган тәгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш.
3. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йортта фатир милекчеләренә исәпләнгән салым суммасын әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрының кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.
Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.
Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

Совет Рәисе
ТР Югары Ослан муниципаль район
Вахитов  авыл җирлеге башлыгы

Ф.Р. Кәримов